ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 396 от «11» 11 2022 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 12 маендагы «Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчалары) гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын яңа редакциядә раслау турында» 138 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Мобилизацияләнгән гражданнарга, контракт буенча хәрби хезмәттә булган гражданнарга, шулай ук һәлак булган хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләренә социаль ярдәм күрсәтү буенча чаралар күрү максатларында, Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 12 маендагы «Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчалары) гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын яңа редакциядә раслау турында» 138 номерлы карарына (алаг таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Карарның 1 нче кушымтасының II бүлегендәге 2.7 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«Контракт буенча хәрби хезмәттә булган гражданнарның балаларына, шулай ук һәлак булган хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләрендәге балаларга, мобилизацияләнгән гражданнарның балаларына мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмасына чираттан тыш керү хокукын бирү (Татарстан Республикасы Мамадыш шәһәре һәм Мамадыш районы Хәрби комиссариаты биргән исемлекләр нигезендә)».

2. Бу карар 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

0000011467

3.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль районының www.mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары М.Р.Хуҗаҗановка йөкләргә.

Җитәкче О.Н.Павлов